МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ
И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ
БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ

---

**ПРИКАЗ** 23.07.2015 | г. Казань | **БОЕРЫК** №530-п

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен раслау хакында**

2003 елның 12 маендагы “Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында” 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясының 3 өлешен үтәү һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшкә анализ үткәргәндә бердәм эш ысулы булдыру максатларында, **боерык бирәм:**

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына (алга таба – Министрлык) гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен расларга.

2. Документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге башлыгы Г.Р. Хәннановага гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ (алга таба – анализ) ясарга.

3. Җыелма бүлек башлыгы Л.В Серовватовага анализның Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Министр А.Г. Сидоров

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе (Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2015 елның 23 июлендәге 530-п номерлы боерыгы белән расланды)**

1. Әлеге Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына (алга таба – Министрлык) гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә (алга таба – мөрәҗәгатьләр) анализ үткәрү тәртибе мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү буенча эш сыйфатын арттыру максатларында эшләнде һәм Министрлыкка килгән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм аларны анализлау процедурасын билгели.

2. Министрлыкка килгән мөрәҗәгатьләрне анализлау тиешле чорда килгән барлык мөрәҗәгатьләрне, шул исәптән: язмача рәвештә, электрон документ рәвешендә, Интернет – рәсми порталның кабул итү хезмәте аша җибәрелгән һәм гражданнарны шәхси кабул итү вакытында килгән мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып башкарыла.

3. Мөрәҗәгатьләрне анализлау мәгълүмат туплау, аны өйрәнү, гомумиләштерү, бәяләү һәм нәтиҗәләр әзерләү юлы белән гамәлгә ашырыла. Шул ук вакытта килүче мөрәҗәгатьләрнең сан һәм сыйфат күрсәткечләре исәпкә алына, төп тематикасы билгеләнә, мөрәҗәгатьләрне карау вакытларын бозу өлешендә башкарма дисциплинаның торышы анализлана.

4. Анализлау нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгатьләр белән эшләү нәтиҗәлелеген, башкару срокларын контрольдә тоту сыйфатын арттыруга ярдәм итүче чаралар исемлеге төзелә.

5. Министрлыкка килгән мөрәҗәгатьләрне анализлау ярты еллык һәм узган ел нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының “Электрон Хөкүмәт” Бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасыннан файдаланып, җаваплы белгеч тарафыннан хисап чоры үткәннән соң ун эш көне дәвамында башкарыла.

6. Министрлыкка килгән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәргәндә министрның, министрның беренче урынбасарының, министр урынбасарларының, эшләр белән идарә итүченең (алга таба – Министрлык җитәкчелеге, гражданнарны шәхсән кабул итү вәкаләте бирелгән затлар) шәхси кабул итүе һәм Министрлык җитәкчелеге тарафыннан урынга чыгып кабул итү вакытында алынган мөрәҗәгатьләр исәпкә алына.

7. Министрлыкка килгән мөрәҗәгатьләргә җаваплы белгеч тарафыннан үткәрелгән анализ нәтиҗәләре буенча тиешле чор өчен Министрлыкта гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү турында аналитик белешмә (алга таба – аналитик белешмә) формалаштырыла.

8. Аналитик белешмә түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш (хисап чоры өчен):

килгән, башка адреска җибәрелгән һәм карап тикшерелгән язмача мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны;

электрон документ рәвешендә килгән, башка адреска җибәрелгән һәм карап тикшерелгән граждан мөрәҗәгатьләренең гомуми саны;

гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре, даталары һәм сәгатьләре турында;

шәхсән кабул итү барышында кабул ителгән гражданнар саны турында;

гражданнарны шәхсән кабул итү һәм урынга чыгып шәхсән кабул итү вәкаләте бирелгән затлар турында;

мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында;

мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү нәтиҗәсендә кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив-хокукый һәм башка төрле актлар (булган очракта) турында мәгълүмат;

гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү нәтиҗәлелеген, аларны башкару сроклары сыйфатын арттыруга ярдәм итүче, кабул ителгән чаралар турында.

9. Тиешле чорда гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләргә үткәрелгән анализ нәтиҗәләре буенча аналитик белешмә Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.eco.tatarstan.ru), "Гражданнарның мөрәҗәгатьләре" бүлегендә хисап чоры үткәннән соң ун эш көне дәвамында урнаштырылырга тиеш.